ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13.04.2023 Баулы шәһәре №95

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә 2023 елга автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль өлкәсендә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау программасын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 октябрендәге 141 номерлы карары, Баулы муниципаль районы Советының «Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль контроле турындагы нигезләмәне раслау турында» 2022 елның 27 октябрендәге 141 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымтадагы Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә 2023 елга автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль өлкәсендә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау программасын расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 13 апрелендәге
95 номерлы карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә 2023 елга автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль өлкәсендә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау программасы

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә 2023 елга автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль өлкәсендә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау программасы (алга таба – Программа) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы 2 нче өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 25 июнендәге 990 номерлы карары белән расланган закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау программасын контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан эшләү һәм раслау кагыйдәләре нигезендә, оешмалар һәм гражданнар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне намуслы үтәүне стимуллаштыру, мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яисә) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү, контрольдә тотылучы затларга мәҗбүри таләпләрне җиткерү өчен шартлар тудыру, аларны үтәү ысуллары турында мәгълүматлаштыруны арттыру максатларында эшләнде.

1.2. Программа Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау чаралары комплексын күздә тота.

1.3. Муниципаль контроль төре: автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль.

1.4. Муниципаль контроль предметы: Баулы муниципаль районы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне гражданнар һәм оешмалар (алга таба - тикшереп торучы затлар) тарафыннан үтәү:

1) автомобиль юлларына карата билгеләнгән таләпләрне:

а) гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының бүленгән полосасында һәм (яисә) юл буе полосаларында урнашкан юл сервисы объектларын эксплуатацияләүгә;

б) автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү өлешендә гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм аларда ясалма юл корылмаларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен гамәлгә ашыруга;

2) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны билгеләнгән таләпләр (автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелек) предметына карамаган).

1.5. Баулы муниципаль районы Советының 2022 елның 27 октябрендәге 141 номерлы карары белән расланган Баулы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы Нигезләмә нигезендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы орган булып Баулы муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитеты) тора.

Автомобиль транспортында муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар булып башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы һәм баш белгече тора (алга таба - автомобиль транспортында муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар). Күрсәтелгән вазыйфаи затларның вазыйфаи бурычларына, аларның вазыйфаи инструкцияләре нигезендә, автомобиль транспортында муниципаль контроль буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру керә.

1.6.Муниципаль контроль предметы булып шулай ук контроль чаралар нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларның үтәлеше дә тора.

1.7. 2023 елга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль өлкәсендә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау кысаларында башкарма комитет түбәндәге чараларны гамәлгә ашыра:

1) Баулы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында норматив хокукый актларны яки аларның мәҗбүри таләпләре булган аерым өлешләре исемлекләрен урнаштыру, шулай ук тиешле норматив

хокукый актлар текстларын урнаштыру аларның үтәлешен бәяләү муниципаль контроль предметы булып тора;

2) мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга мәгълүмат җиткерү, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча белешмәлек әзерләү һәм бастырып чыгару, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре юлы белән.

## 2. Программаны гамәлгә ашыруның максатлары һәм бурычлары

2.1. Профилактика эшенең максатлары түбәндәгеләр:

1) барлык контрольдә тотыла торган затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне намуслы үтәүне стимуллаштыру;

2) мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яисә) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян салуга китерергә сәләтле шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү;

3) мәҗбүри таләпләрне контрольдә тотылучы затларга җиткерү өчен шартлар тудыру, аларны үтәү ысуллары турында мәгълүмат бирүне арттыру;

4) контрольдә тотыла торган затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуны кисәтү, мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерү;

5) контрольдә тотыла торган затларга административ йөкләнешне киметү;

6) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә китерә торган зыян күләмен киметү.

2.2. Профилактика эшенең бурычлары түбәндәгеләр:

1) мәҗбүри таләпләрне бозуны профилактикалау системасын ныгыту;

2) мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны ачыклау, мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар эшләү;

3) карала торган хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә оешмаларның һәм гражданнарның хокукый аңын һәм хокукый культурасын арттыру.

## 3. Профилактик чаралар исемлеге, аларны уздыру сроклары (вакыты)

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2022 елның 27 октябрендәге 141 номерлы карары белән расланган Баулы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы Нигезләмә нигезендә түбәндәге профилактик чаралар уздырыла:

| Чара исеме | Чара эчтәлеге | Чараны тормышка ашыру срогы |
|---|---|---|
| 1. Мәгълүмат бирү | Тиешле белешмәләрне урнаштыру юлы белән мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча Баулы муниципаль районының рәсми сайтында мәгълүмат бирү | даими |
| 2. Хокук куллану практикасын гомумиләштерү | Үткәрелгән контроль чаралар һәм аларның нәтиҗәләре турындагы мәгълүматларны җыю һәм анализлау юлы белән хокук куллану практикасын гомумиләштерү. Хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган докладны әзерләү, ул контроль орган җитәкчесе тарафыннан раслана. | хокук куллану практикасын гомумиләштерү елыннан соңгы елның 30 гыйнварыннан да соңга калмыйча ел саен |
| 3. Кисәтү белдерү | Башкарма комитетта мәҗбүри таләпләрне бозачак хокук бозулар турында мәгълүмат булган очракта контрольдә тотыла торган затка мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү белдерү | законнарда каралган нигезләр барлыкка килгән саен |
| 4. Консультация бирү | Телефон аша, видеоконференцэлемтә аша, шәхси кабул итүдә, профилактик чара, контроль (күзәтчелек) чарасы үткәрү барышында консультация бирү | контрольдә тотучы затлар һәм аларның вәкилләре мөрәҗәгатьләре буенча даими рәвештә |
| 5. Профилактик визит | Контрольдә торучы зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча профилактик визит формасында профилактик әңгәмә йә видеоконференцэлемтә юлы белән. Профилактик визит барышында контрольдә тотыла торган зат аның эшчәнлегенә | елына бер тапкыр |

| | | |
|---|---|---|
| | яисә аның объектларына карата куела торган мәҗбүри таләпләр турында мәгълүмат бирә | |

Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында профилактик чаралар үткәрү буенча җаваплы вазыйфаи затлар булып Баулы муниципаль районы территориясендә Баулы муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы һәм баш белгече тора.

4. Программаның нәтиҗәлелегә күрсәткечләре

| № п/п | Күрсәткеч исеме | Зурлыгы |
|---|---|---|
| 1. | «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2021 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Баулы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган мәгълүмат тулылыгы | 100% |
| 2. | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган докладны раслау, аны бастырып чыгару | башкарылган / башкарылмаган |
| 3. | Мәҗбүри таләпләрне бозачак хокук бозулар турында яисә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында расланган белешмәләр белән мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча бирелгән кисәтүләр өлеше (%) | 20% һәм күбрәк |
| 4. | Консультированиене сорап мөрәҗәгать иткән затларның гомуми санында консультацияләүдән канәгать булган затлар өлеше | 100% |